СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.05.2021 Баулы шәһәре № 53

Баулы муниципаль районы Советының
2014 елның 11 ноябрендәге «Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль районы»
муниципаль берәмлегендә муниципаль
вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы
гражданнар керемнәре, мөлкәтләре һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында
белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы
«Баулы муниципаль районы» муниципаль
берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче
затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары,
мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру
хакындагы нигезләмәне раслау турында»
239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына һәм «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ

номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Баулы муниципаль районы уставы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» 239 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Советының 2015 елның 20 апрелендәге 260 номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 241 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 7 пунктның «в» пунктчасында «оешмалар») сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

2. 13 пунктта «оешмалар») сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

3. кушымтада «оешмалар,») сүзеннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта,» сүзләрен өстәргә;

4. 7 пунктның 7.1 пунктчасында «ресурс» сүзеннән соң «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында (dohod.tatar.ru)» сүзләрен өстәргә;

5. 7 пунктның 7.1 пунктчасында «хисап чорыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта» сүзләренә алмаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин